# Антонимнар

1 нче төркем



# Антонимнар

капма –каршы мәгънәле сүзләр

даими

контекстуаль



# Антонимнарга хас үзенчәлекләр:

- Бөтен сүзләрнең дә антонимнары булмый.
- Сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәрендә антонимнар күп очрый, чөнки алар билге белдерә.
- Даими антонимнар (тел антонимнары) контексттан тыш та антоним булалар, алар һәрвакыт капма-каршы мәгънәле.
- Контекстуаль антонимнар билгеле бер контекстта гына антоним булалар.
- Антонимнардан парлы сүзләр күп ясала.
- Әдәбиятта антоним сүзләрдән сурәт ясау антитеза дип атала.
- Антонимнар мәкальләрдә, җырларда, табышмакларда күп очрый.
- Сөйләмдә антонимнарның сүзтезмә ясап бәйләнешкә керүе оксюморон дип атала.

Табигать күренешләрен күрсәтәләр: җылы-салкын, аяз-болытлы...

Күренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатлан белдерәләр: ак-кара, таза-ябык...

Вакыт төшенчәсен белдерәләр: көн-төн, яз-көз...

## Антонимнарның төркемчәләре

Күренешләрнең озынлыгын, күләмен, урнашуын ачыклыйлар: аз – мул, озын-кыска...

Процессларны каршы куялар: бару-кайту, туу-үлү...

Гомумирәк төшенчәләрне белдерәләр: байлык-ярлылык, сугыш-тынычлык...

# Антонимнарны тап !

1. Күпме җырлар оттым
   һәм оныттым,
   Тик арышлар җырын онытмам. (Ф.Шәфигуллин)

2. Җырлый-җырлый күтәреләм
   Тормышның үрләренә.
   Шатлыгым да, хәсрәтем дә
   Тик туган җирдә генә. (Р.Рәсимов)

3. Үлгәннәрнең каберен бел,
   Исәннәрнең кадерен бел! (Ш.Галиев)

4. Агыйделдән көймә килә
   Чит-чите буйлап кына.
   Ак йөзләрем сары булды
   Гел сине уйлап кына. (Җыр)



# Антонимнар

оттым- оныттым
шатлыгым-хәсрәтем
үлгәннәрнең-исәннәрнең

ак- сары

даими

контекстуаль



# Даими һәм контекстуаль антонимнарны билгеләгез.

1.Картлар сүзен капчыкка сал,
яшьләр сүзен янчыкка сал. (М.)

2. Җырлый белмиләр бөркетләр,
Сугыша белми былбыл.
Җырдан сызланмый бөркетләр
Сугышта үлми былбыл. (Зөлфәт)

3. Туры әйткән котылган,
ялганлаган тотылган. (М.)

4. Яхшы сүз - җан азыгы,
яман сүз - баш казыгы. (М.)

5. Мин үзем дә белми торган
Бер сәерлектә яшим.
Челләләрдә кайчак өшим,
Кышларын ярсып яшьним. (Р. Ф.)

картлар-яшьләр- *даими*

җырлый-сугыша- *контекст.*

бөркет-былбыл- *контекст.*

туры әйткән-ялганлаган -*даими*

котылган-тотылган -*даими*

яхшы-яман - *даими*

челләләрдә - кышларын–*контекст.*

Өшим-яшьним- *контекст.*

# Антонимнарның нинди сүз төркеменә керүен билгеләгез

чиста-пычрак, бай-ярлы, тәмле-тәмсез
- яхшы-яман, таза-ябык, юмарт-саран,

**сыйфат**

- яз-көз, җир-су, яшәү-үлем, җәй-кыш

**исем**

- аз- күп, быел-былтыр, югары-түбән

**рәвеш**

- туа-үлә, ята-тора, арта-кими,
 бара-кайта, чыга-керә, туңа-җылына

**фигыль**



# Синоним һәм антонимнарны яз

| синоним | | антоним |
|---|---|---|
| чибәр, сылу, зифа | матур | ямьсез, килбәтсез, шыксыз |
| эре, дәү, олы, өлкән | зур | нәни, вак, кечкенә |
| хак, чын, рас, тугры | дөрес | ялган, алдау |
| кызу, кайнар | эссе | суык, салкын |
| әйбәт, шәп, ару | яхшы | начар, яман, әшәке |
| иптәш, сердәш, ахирәт | дус | дошман |
| | | |



**Көн дә кирәкле мәкальләр һәм әйтемнәр:**

Үсәр өчен артка түгел, алга карарга кирәк.

Гыйлемлек – нур, наданлык – хур.

Тыйнакның кулы эшләр, мактанчыкның теле эшләр.

Дөньяда иң татлы нәрсә дә тел, иң ачы нәрсә дә тел.



Күңел күкләрегез аяз булсын!